**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт. Тел.3-44-56

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«20» ноябрь 2019 ел** **№ 30**

6.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Кормаш авыл җирлеге гражданнары җыены **карар итте**:

1. Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 Төркем инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләүләр кертергә.:
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлүне оештыру: су челтәрләрен ремонтлау, тоту, торак пунктларда су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: авылларда урамнарны яктырту, Кыркентүбә авыл клубы коймасын ремонтлау, хуҗасыз милекләргә койма тоту, авыл җирлеге территориясендә агачлар кисү;
- Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү: Сабантуй территориясен төзекләндерү;
-Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Кыр-Каентүбә, Шабизбаш авылларына, Иске Кормаш авылының Ә. Сәфәргалин урамына вак таш салу, Иске Балтач һәм Яңа Балтач авыллары арасындагы күперне һәм юлларны ремонтлау, грейдерлау, кардан чистарту, юлларны һәм күперләрне ремонтлау.;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту: зиратларны документаль рәсмиләштерү, инвентарь алу, Шабизбаш авылы зиратын койма белән әйләндереп алу;;
- җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: янгын гидрантларын, янгын краннарын урнаштыру, янгын җиңсәләрен алу;
-җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;;
- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;

2. Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге гражданнарының җыен нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Авыл башлыгы И. А. Кашбразиев